СОВЕТ БАВЛИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БАУЛЫ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

25.05.2023 Баулы шәһәре №184

Баулы муниципаль районы Советының
«Балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның
хокукларын яклау комиссиясе турында»
2020 елның 15 декабрендәге 25 номерлы
карарына үзгәрешләр кертү хакында

Баулы муниципаль районы Советы КАРАР ИТТЕ**:**

Баулы муниципаль районы Советының «Баулы муниципаль районы балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау комиссиясе турында» 2020 елның 15 декабрендәге 25 номерлы карары белән расланган Баулы муниципаль районы балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау комиссиясе составына (Баулы муниципаль районы Советының 2012 елның 6 августындагы №63, 2022 елның 11 апрелендәге, № 108, 2022 елның 26 мандагы № 117, 2022 елның 18 августындагы № 121, 2022 елның 27 октябрендәге №144 карарлары нигезендә кертелгән үзгәрешләр белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1. Комиссия составына кертергә:

- Сабиров Илмир Әнвәр улын - «Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районының спорт һәм туризм үсеше бүлеге» МКУ начальнигын (килешү буенча).

- Моратова Рәмзия Әнәс кызын - «Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районының мәдәният бүлеге» МКУ начальнигын (килешү буенча),

- Хәлиуллина Альбина Камил кызын - Баулы муниципаль районының ветераннар (пенсионерлар) иҗтимагый оешмасы рәисе (килешү буенча).

2. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Баулы муниципаль районы Советының җирле үзидарә, законлылык, хокук тәртибе һәм депутат этикасы мәсьәләләре буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Баулы муниципаль районы Башлыгы,
район Советы рәисе И.И. Гозәеров